**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6981**
**23.11.2018**

«Нардуган» халык-йола
бәйрәме үткәрү турында

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 нчы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, милләтара элемтәләрне һәм Татарстан Республикасы халыкларының дуслыгын ныгыту һәм шәһәр халкының ялын оештыру максатында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә 2019 елның 20 гыйнварында Яр Чаллы шәһәренең «Сара Садыйкова исемендәге концертлар залы» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә «Нардуган» халык-йола бәйрәме үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Нардуган» халык-йола бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Нардуган» халык-йола бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «Нардуган» халык-йола бәйрәмен оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 50 000 (илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6981 нче карарына
1 нче кушымта

«Нардуган» халык-йола бәйрәменә
әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Агапов Виталий Васильевич | Шәһәр Советы депутаты, Татарстан халыклары Ассамблеясының Яр Чаллы филиалы җитәкчесе, Яр Чаллы керәшен мәдәни-агарту җәмгыяте рәисе (килешенү буенча) |
| 3. | Галиуллин Рөстәм Рәфыйк улы | Башкарма комитетның җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге башлыгы |
| 4. | Ишалина Ландыш Риф кызы | Яр Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе директоры (килешенү буенча) |
| 5. | Мөхәммәтҗанова Римма Равил кызы | Башкарма комитетның икътисадый сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| 6. | Ногманова Эльвира Илшат кызы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 7. | Салихов Фәнил Сабирҗан улы | Яр Чаллы шәһәренең «Сара Садыйкова исемендәге концертлар залы» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе директоры. |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6981 нче карарына
2 нче кушымта

«Нардуган» халык-йола бәйрәменә
әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар
планы

| | Чараның исеме | Үтәү срогы | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Бәйрәмгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты киңәшмәсен үткәрү | билгеләнеш буенча | Хәлимов Р.М. |
| 2. | Кунакларны, артистларны, иҗат коллективларын чакыруны тәэмин итү | 10.01.2019 башлап | Ногманова Э.И. Ишалина Л.Р. |
| 3. | Массакүләм мәгълүмат чараларында анонс урнаштыруны тәэмин итү | 10.01.2019 башлап | Мөхәммәтҗанова Р.Р. |
| 4. | Бәйрәм сценариен һәм программасын әзерләү | 14.01.2019 кадәр | Ногманова Э.И. Ишалина Л.Р. |
| 5. | Сәхнә бизәү эшен оештыру | 19.01.2019 | Ногманова Э.И. Ишалина Л.Р. |
| 6. | Бәйрәмдә тавыш яңгырашын тәэмин итү | 20.01.2019 | Ногманова Э.И. Ишалина Л.Р. |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6981 нче карарына
3 нче кушымта

«Нардуган» халык-йола бәйрәмен
үткәрүгә чыгымнар
сметасы

<table>
<tr><th>Т/с</th><th>Исеме</th><th>Сумма, (сум)</th><th>Җаваплы</th></tr>
<tr><td>1.</td><td>Йола җырларының һәм көйләренең фонограммасын яздыру</td><td>25 000,00</td><td rowspan="3">«Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» МАМУ</td></tr>
<tr><td>2.</td><td>Ут техникасы һәм тавыш аппаратурасы белән тәэмин итү</td><td>25 000,00</td></tr>
<tr><td colspan="2">барлыгы:</td><td>50 000,00</td></tr>
</table>

Барысы: 50 000 (илле мең) сум 00 (ноль) тиен.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева